*Көнчыгышта урнашкан ул*
*Горур шәһәр - Бөгелмә.*
*Татарстан җирлегендә*
*Белми аны кем генә!*
*Бөгелмә, Бөгелмә*
*Күңелемнең түрендә.*
*Гөрләп үсә Бөгелмәбез*
*Татарстан җирендә.*





# Бөгелмә муниципаль районы
# 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе



8 нче сыйныф укучысы
Шәмсиев Руслан



Яраткан дәресләрем: рус теле һәм әдәбияты, тарих, татар теле һәм әдәбияты.

Яраткан шөгылем: почта маркалары һәм кулланыштан чыккан акчалар җыю




# Туган якны өйрәнү музеена экскурсия.

Исәнмесез, кадерле кунаклар!

Безнең туган якны өйрәнү музеена рәхим итегез.

Сезнең алдыгызда борынгы татар өе. Өйнең иң күркәм өлеше сәке булган. Ул – болгар бабаларыбыздан калган мирас. Татар халкы сәке белән мең елдан артык файдаланган. Хәзер дә авылларда ялгыз яшәүче әби-бабайларның өйләрендә сәкеләр очратырга мөмкин. Сәке йоклау, ял итү, ашау урыны булган. Аның өстенә кулдан матур итеп тукылган палас җәелгән, як-ягына мендәрләр, юрганнар өелеп куелган. Ашаганда уртасына ашъяулыкка самавыр һәм кәсәләр тезелгән, аның тирәсендә түгәрәкләшеп утырып чәй эчкәннәр. Борынгыдан ук татар өйләре чисталыгы, матурлыгы белән дан тоткан. Хатын-кызлары кечкенәдән үк кул эшләренә бик оста булганнар: чигү чиккәннәр, бәйләм бәйләгәннәр, йон-сүс эрләгәннәр. Өй эче чигүле әйберләргә мул булган. Өйнең түрендәге стенага түрләмә эленгән. Көзге өсләренә, стенага чигүле сөлгеләр элеп куелган. Мендәрләргә чигүле тышлар кидерелгән. Караватка, өстәлләргә чигүле бөркәүләр җәелгән.

Сабантуйлары, бәйрәмнәр өчен аерым сөлгеләр, кулъяулыклар чигелгән. Кызлар үзләренә чигүле бирнә әзерләгәннәр, аларны атап алынган сандыкка җыйганнар. Яшь килен егет өенә шул сандыгы белән төшкән. Ул чиккән әйберләре белән кияү йортын карап туймаслык матур дөньяга әверелдергән. Сабый бала туар алдыннан бишек ясап куелган. Ул пружина яки бау ярдәмендә түшәмгә эленгән. Әбиләр, әниләр бишекне тирбәтә-тирбәтә балага җыр җырлаганнар. Бишек җыры аркылы аңа әти-әнисенең йөрәк җылысы, иң гүзәл, иң изге саф хисләре җиткерелгән. Бала уянмасын өчен бишекнең тирә-ягын чыбылдык белән каплаганнар.

Ә хәзер сезнең каршыгызда эш кораллары. Каба ярдәмендә йон эрләгәннәр, ә байлар йон эрли торган машина кулланганнар. Ә монысы – җепката торган җайланма. Йоннан бияләй, шәл, оекбаш, тула оеклар бәйләгәннәр, шулай ук паласлар да сукканнар. Ә бу – йон эрли торган машинаның өлешләре. Тәрешле тарак – ул сүс эрләү җайланмасы.

Сезнең алдыгызда йон, мамык һәм киндер тукымалары. Алардан кием-салым теккәннәр. “Күркәм кием – тән зиннәте”, - ди халкыбыз. “Гомумән, татар мөселманнары вә аларның хатыннары ачыграк, матуррак булганны яраталар”, - дип яза Каюм Насыйри милли кием-салымнарыбызга карата. Сезнең алдыгызда – милли киемнәр. Татар хатын-кызлар кийеменең иң күркәм өлеше калфак яки матур яулык, бәбәй итәкле күлмәк, укалы камзол, чулпылар булган. Аякларына бизәкле читек яки чүәк кигәннәр.

Ә хәзер искә төшереп китик, безнең әби-бабайларыбыз ничек итеп уңыш җыйганнар. Алар игенне урак белән урганнар, көлтәләргә куеп киптергәннәр. Ындыр табагында чабагачлар белән сугып, бодайны саламыннан аерганнар. Чистартылган бодайны тегермәндә тартып он ясаганнар. Он иләк ярдәмендә юлпычка салып иләнгән. Күәскә ипи изгәннәр, яхшы кабарсын өчен камырга колмактан баш ясап салганнар. Мичкә утын якканнар, ә ул янып беткәч, кисәү агачы ярдәмендә күмерне алга тартканнар. Ипине агач көрәккә куеп мичкә тыкканнар һәм мич калае белән томалап пешергәннәр. Бәлеш, өчпочмак, гөбәдия, кабартма, коймак һ.б. төрле азыклар мичтә әзерләнгән. Ә чәкчәк,аш казанда пешерелгән. ...

# МУЗЕЙДАН КҮРЕНЕШЛӘР









# МИНЕМ ЭЗЛӘНҮЛӘРЕМ, АЧЫШЛАРЫМ…



Кытырлы бәләк – агач үтүк.



Кайнар күмер салып эшли торган үтүкләр







## Рәсәй музей педагоглары берләшмәсенең алтын кагыйдәләре:

- Үзеңнең һәм тирә-яктагыларның абруен төшермә!
- Музей әйберләрен сакла!
- Мәдәният чыганагы бул!
- Белемеңне арттыру өстендә эшлә!

ДӨНЬЯ ҮЗЕ - МУЗЕЙ.